КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1275

Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Хайваннарга карата җаваплы мөгаләмә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге ФЗ-498 номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2019 елның 27 декабрендәге ТРЗ-120 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалары булмаган хайваннар белән мөгаләмә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 февраль, 126 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 февраль, 126 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 30 июль, 556 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибен раслау турында» 2013 ел, 22 февраль, 126 нчы карары белән расланган

Татарстан Республикасында хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тоту һәм аларның санын җайга салу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 6 июль, 488 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин